ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 сентябрь 2021 ел № 6267

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмә

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен тиешенчә карап тоту һәм төзекләндерүне тәэмин итү максатында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 25 пункты, 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы, 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Административ-техник инспекция идарәсенә элмә такталар, игъланнар, листовкалар һәм башка тышкы мәгълүмат урнаштыру кагыйдәләрен бозган затларга хәбәр итү хезмәтен күрсәтүче оешмаларны билгеләүгә заявкалар һәм техник йөкләмәләр әзерләүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 24 сентябрендәге
6267 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәүне тәэмин итү максатында эшләнде, ул Башкарма комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә әлеге максатлар өчен каралмаган урыннарда урнаштырылган элмә такталар, игъланнар, листовкалар, газеталар, плакатлар, афишалар, реклама проспектлары һәм башка тышкы мәгълүмати басма продукцияләрне (алга таба – мәгълүмати материал) ачыклаганда автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Әлеге нигезләмәне тормышка ашыру максатында түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

- абонент – элмә такталар, игъланнар, листовкалар һәм башка тышкы мәгълүмат урнаштыру кагыйдәләрен бозган, элемтә өчен телефон номеры билгеләнмәгән урында урнаштырылган мәгълүмати материалда күрсәтелгән зат;

- автомат шалтырату – урнаштырылган мәгълүмати материалда күрсәтелгән телефон номерына автомат шалтырату юлы белән абонентны автомат рәвештә күп тапкыр чакыру;

- вазыйфаи зат – мәгълүмати материалны урнаштыру тәртибен бозган өчен административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтләр бирелгән зат;

- оператор – «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 4 номерлы 4-ФЗ Федераль законы нигезендә элмә такталар, игъланнар, листовкалар һәм башка тышкы мәгълүмат урнаштыру кагыйдәләрен бозган затларга хәбәр итү хезмәте күрсәтү өчен сатып алулар нәтиҗәсендә билгеләнгән оешма.

2 бүлек. Автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе

3. Автомат шалтырату оештыру өчен нигез булып вазыйфаи зат тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә билгеләнмәгән урында мәгълүмати материал урнаштыру факты ачыклану тора.

4. Кагыйдә бозып урнаштырылган мәгълүмати материалны ачыклау вазыйфаи зат тарафыннан турыдан-туры ачыклау юлы белән, шулай ук физик һәм юридик затлардан кергән хәбәрләр һәм гаризалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Физик һәм юридик затлардан кагыйдә бозып урнаштырылган мәгълүмати материал турында хәбәрләр һәм гаризалар кергәндә, вазыйфаи зат андый хәбәр һәм гариза теркәлгән көннән башлап ике эш көне эчендә мәгълүмати материалның күрсәтелгән урында урнашу фактын тикшерә.

6. Мәгълүмати материалны турыдан-туры ачыклау юлы белән ачыклаганда, кагыйдә бозуны вазыйфаи зат тарафыннан фотофиксацияләү башкарыла, әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча тикшерү акты, шулай ук әлеге нигезләмәгә

2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча верификация акты төзелә.

7. Вазыйфаи зат әлеге нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны төзү көненнән башлап бер эш көне эчендә операторга әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча автомат шалтыратуны гамәлгә ашыру кирәклеге турында хәбәр бирүне тәэмин итә.

8. Тавышлы хәбәр биреп автомат шалтыратканда тапшырыла торган текст түбәндәге эчтәлектәге текстка туры килә:

«Хәерле көн! Сезнең телефон Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен бозып, әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән урыннарда урнаштырылган мәгълүмати материалда күрсәтелгән. Тулырак мәгълүмат алу һәм автомат мәгълүматны өзү өчен, Сезгә Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсенә (Х. Туфан урамы, 23 йорт, 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр) мөрәҗәгать итәргә кирәк.

9. Автомат шалтырату көн саен эш көннәрендә 9.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр башкарыла. Ял, эш көне булмаган һәм бәйрәм көннәрендә автомат шалтырату башкарылмый.

## 3 бүлек. Автомат шалтыратуны туктату

10. Әлеге нигезләмәнең 12 пунктында каралганча, автомат шалтыратуны автомат шалтыратуның срогы чыкканчы туктату өчен нигез булып вазыйфаи зат тарафыннан автомат шалтырату оештыруга сәбәп булып хезмәт иткән рөхсәтсез урнаштырылган мәгълүматны алу фактын билгеләү тора.

11. Автомат шалтырату автомат шалтырату гамәлгә ашырыла башлаган көннән алып ике календарь ай беткәч туктатыла, әлеге нигезләмәнең 12 – 15 пунктларында күрсәтелгән очраклар булмаганда.

12. Мәгълүматны рөхсәтсез урнаштыруга юл куйган зат тавышлы хәбәрдә күрсәтелгән адрес буенча килә һәм автомат шалтыратуны өзү турында (4 нче кушымта) гариза бирә ала.

13. Вазыйфаи зат тарафыннан мәгълүматны рөхсәтсез урнаштыруга юл куйган затка карата Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексының 3.5 статьясы буенча административ хокук бозу буенча беркетмә төзелә.

14. Вазыйфаи зат, мәгълүматны рөхсәтсез урнаштыруга юл куйган заттан гариза кабул ителгән һәм административ хокук бозу буенча беркетмә төзелгән көннән башлап бер эш көне эчендә операторга әлеге нигезләмәгә 5 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча автомат шалтыратуны өзү кирәклеге турында хәбәр итә.

15. Автомат шалтыратулар оператор тарафыннан вазыйфаи заттан мәгълүмат алу вакытыннан башлап бер эш көне эчендә туктатыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә
1 нче кушымта
(Форма)

______________________________________________________________
(учреждение исеме)

__________20____ел
________сәг.___ ______мин.

Яр Чаллы шәһәре

Тикшерү акты
№__________

Минем тарафтан,____________________________________________________________,
(вазыйфаның тулы исеме, Ф.И.А.и.)
тикшерү үткәрелде
(объект)
____________________________________________________________ катнашында[1],
(Ф.И.А.и., яшәү урыны адресы, телефон)

аның нәтиҗәләре буенча
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

билгеләнде
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
________________________________________________________________________.

(кагыйдә бозу вакыйгасы, урыны, пункты һәм статьясы төгәл тасвирлап күрсәтелә)

Тикшерү барышында башкарылды: визуаль тикшерү, фотога төшерү.

Актка ___битле,___нөсхәдә фототаблица теркәлә.

Башка тикшерүдә катнашучылар Россия Федерациясе Конституциясенең 51 статьясы, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 17.9, 25.6 статьялары белән таныштылар:

1.______________________________________ ______________
(Ф.И.А.и.) (имза)

2.______________________________________ ______________
(Ф.И.А.и.) (имза)

Тикшерү үткәргән вазыйфаи зат:

_____________________________ ______________
(Ф.И.А.и.) (имза)

________________________

[1] Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 25.6 статьясы нигезендә билгеләнергә тиеш вакыйгалар таныш булган зат барында гына.

______________________________________________________________

(учреждение исеме)

ФОТОТАБЛИЦА

20______________ел. №______________тикшерү актына

Урыны: ______________________________________________________________.

| |
|---|
| Фотография<br>(төсле) |

_____________________________/__________

(Ф.И.А.и.) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Форма)

Верификация (тикшерү) акты

«___»___________20___ Яр Чаллы шәһәре

Минем тарафтан,___________________________________________________________

______________________________________________________________________

(вазыйфа, Ф.И.А.и.)

рөхсәтсез урнаштырылган мәгълүматта күрсәтелгән

____________________телефон номерына шалтыратылды. Әлеге телефон абоненты белән телефоннан сөйләшү барышында өстә күрсәтелгән телефон номерының түбәндәгеләр өчен файдаланылуы билгеләнде

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________.

(хезмәтләр яки товарлар күрсәтелә)

___________________________/____________

(Ф.И.А.и.) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә
3 нче кушымта
(Форма)

___________________________
(оператор реквизитлары)

Административ хокук бозуның ачыкланган
фakты һәм автомат шалтыратуны гамәлгә
ашыруның кирәклеге турында мәгълүмат

Түбәндәге таблицадагы телефон номерлары буенча автомат шалтырату тоташтыруыгызны сорыйм.

| Телефон номеры (игъланнан) | Кагыйдә бозуны ачыклау датасы, вакыты һәм урыны | Кагыйдә бозуны ачыклаган зат | Игълан тексты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

______________________________/_____________
(Ф.И.А.и.) (имза)

-
____________________
,(Ф.И.А.и.)
тел.: __________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә
4 нче кушымта
(Форма)

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитетының
административ-техник инспекция
идарәсе башлыгы

_______________________________

____________________________________

(Ф.И.А.и. – физик затлар өчен)

___________________________________,

адресы буенча яшәүче:

____________________________________

____________________________________;

______________________________________

____________________________________,

(оешма исеме – юридик затлар өчен)

адрес:______________________________,

ИНН:_______________________________,

ОГРН:______________________________,

тел.:________________________________,

Гариза

Яр Чаллы шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең ___пункты таләпләрен бозып, _______________________________адресы буенча минем тарафтан рөхсәтсез урнаштырылган мәгълүматта күрсәтелгән телефон номеры буенча ________________автомат шалтыратуны өзүегезне сорыйм, аның өчен Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында Кодексының 3.5 статьясы буенча җаваплылык каралган.

___________________________/___________
(дата) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомат шалтырату оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә
5 нче кушымта
(Форма)

________________________
(оператор реквизитлары)

Автомат шалтыратуны өзү кирәклеге турында оператор өчен мәгълүмат

Түбәндәге телефон номерлары буенча автомат шалтыратуны өзүегезне сорыйм:

1)____________________________________________,

2)____________________________________________,

3)____________________________________________.

____________________________/
____________________________
(Ф.И.А.и.) (имза)

__________________,(Ф.И.А.и.)
тел.:____________